**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 сентябрендәге 3959 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3850 номерлы «Казанда «Казан ярыммарафоны – 2024» җиңел атлетика чарасы үткәрү, чараны әзерләү һәм үткәрү чорына транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнар һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законы белән, шулай ук Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә караган ЮХИДИ бүлекчәсе тәкъдимнәренә бәйле рәвештә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3850 номерлы «Казан шәһәрендә «Казан ярыммарафоны – 2024» җиңел атлетика чарасын уздыру һәм чараны әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 1.1 пунктына «әлеге карарга:» сүзләреннән соң түбәндәге абзацларны өстәргә:

«- 2024 елның 21 сентябрендә 14:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр Подлужная урамы буенча (Толстой урамыннан «Миллениум» күперенә кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 21 сентябрендә 14:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр Вишневский урамыннан Подлужная урамына чыгу урыны (хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 21 сентябрендә 14:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр «Миллениум» күпереннән Подлужная урамына чыгу урыны (хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр Подлужная урамы буенча (Толстой урамыннан «Миллениум» күперенә кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү)»;

1.1.2. 1.3 пунктындагы «шулай ук катнашучылар хәрәкәтенең бөтен маршруты буенча яктыртуны тәэмин итәргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.3. 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә: «Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәләхетдинов) ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигына төзәтмәләр кертергә, чараны әзерләгәндә, транспортның керү юлларын һәм машина кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чүп баклары билгеләп куярга һәм үткәрү урыннарында чүп чыгаруны тәэмин итәргә, чара тәмамланганнан соң, үткәрү урыннарына якын урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, Казан шәһәре Башкарма комитеты районнарының администрацияләре белән берлектә йөк техникасы белән юлларны ябуга ярдәм итүне оештырырга, шулай ук катнашучылар хәрәкәтенең бөтен маршруты буенча яктыртуны тәэмин итәргә».

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны урнаштырырга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) спортчылар хәрәкәте вакытында күрсәтелгән участоклар буенча транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә **тәкъдим итәм.**

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**